ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2020 ел № 38/6

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль законга нигезләнеп

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге № 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктта «Дәүләт һәм муниципаль милекне сату буенча конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 12 августындагы 584 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, «Аукционда дәүләт яки муниципаль милекне сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне һәм махсус аукционда дәүләт яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 585 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, «Дәүләт яки муниципаль милекне гавами тәкъдим белән һәм бәя игълан итмичә сатуны оештыру турындагы Нигезләмәләрне раслау турында 2002 елның 22 июлендәге 549 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары» сүзләрен «Дәүләт яки муниципаль милекне сатуны электрон формада оештыру һәм үткәрү турында» 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары» сүзләренә алыштырырга;

2) 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча белән тулыландырырга:

12) «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Россия

Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек милкенә милек взносы сыйфатында идарәче компания мөлкәтенә бирелә торган мөлкәт.»;

3) 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:

«4.1. Арендалана торган муниципаль күчемсез милекне хосусыйлаштыруда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашу үзенчәлекләре Федераль закон белән билгеләнә.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев